# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Җир турындагы законнарны бозган өчен административ җаваплылык хакында

Әлеге Закон Татарстан Республикасы территориясендә җир турындагы законнарны бозган өчен хокукый һәм физик затларның, гражданнарның хокукый җаваплылыгын билгели һәм ул җирдән нәтиҗәле файдалануны, аны саклауны тәэмин итүгә юнәлтелгән.

1 статья. Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез алу һәм рөхсәтсез төзү

Җир кишәрлекләрен рөхсәтсез алган, рөхсәтсез төзегән, шулай ук урындагы затларның җирләрне рөхсәтсез алуга китерә торган хокукка каршы кылган гамәлләре өчен хокукый затларга - сиксәннән алып ике йөз минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга икедән алып биш минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

2 статья. Туфракның уңдырышлы катламын бозу

Төзелеш эшләрен башкарганда, файдалы казылмаларны эшкәрткәндә туфракның уңдырышлы катламын саклау гамәлләрен үтәмәү аркасында аның уңдырышлы катламын бозган һәм шулай ук әлеге катламны рөхсәтсез җыеп алган өчен хокукый затларга - йөздән алып өч йөз минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, граж-

даннарга икедән алып биш минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

3 статья. Сәнәгать калдыклары, агып төшкән сулар, агулы һәм радиоактив матдәләр белән пычрату, бактериаль-паразитик һәм карантин организмнары белән агулау аркасында туфрак катламын бозу

Сәнәгать калдыклары, агып төшкән сулар, агулы һәм радиоактив матдәләр белән пычрату, бактериаль-паразитик һәм карантин организмнары белән агулау аркасында туфрак катламын бозган өчен хокукый затларга - ике йөздән алып биш йөз минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга икедән алып биш минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

4 статья. Җирләрне хуҗаларча файдаланмау һәм җирләрне максатка яраксыз файдалану

Җирләрне хуҗаларча файдаланмаган, ягъни җирләрне яхшырту буенча, аларны су һәм җил эрозиясеннән һәм туфракны начарландыруга китерә торган башка гамәлләрдән саклау буенча мәҗбүри чараларны үтәмәгән өчен, авыл хуҗалыгы җирләрен чүп үләннәреннән арындырмаган өчен, шулай ук җирләрне максатка яраксыз файдаланган өчен урындагы затларга - өчтән алып җиде минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга бердән алып өч минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

5 статья. Вакытлыча алынган җир кишәрлекләрен кайтарып бирү вакытын үтәмәү

Вакытлыча алынган җир кишәрлекләрен кайтарып бирү вакытын үтәмәгән яисә аларны максатка ярашлы файдалану өчен тиешле халәткә китерү йөкләмәләрен үтәмәгән өчен хокукый затларга

йөздән алып ике йөз минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга бердән алып өч минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

6 статья. Җирне файдалану чикләренең ызан тамгаларын бозу

Җирне файдалану чикләренең ызан тамгаларын бозган өчен урындагы затларга - өчтән алып җиде минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга бердән алып өч минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Җирләрнең торышына тискәре йогынты ясаучы объектларны урнаштыру, төзү һәм аларны файдалануга тапшыру

Җирләрнең торышына тискәре йогынты ясаучы объектларны урнаштырган, төзегән һәм файдалануга тапшырган өчен хокукый затларга - ике йөздән алып биш йөз минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга биштән алып ун минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Җир фондының барлыгы хакындагы мәгълүматны яшереп калу һәм җирләрнең торышы, аларны файдалану турындагы белешмәләрне бозып күрсәтү

Җир фондының барлыгы хакындагы мәгълүматны яшереп калган һәм җирләрнең торышы, аларны файдалану турындагы белешмәләрне бозып күрсәткән өчен урындагы затларга - бердән алып өч минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга 0,5 тән алып бер минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. Табигатьне саклау, кешеләрне сәламәтләндерү, ял итү, тарихи-мәдәни максатларда җирләрне файдалануның билгеләнгән режимын бозу

Табигатьне саклау, кешеләрне сәламәтләндерү, ял итү, тарихи-мәдәни максатларда җирләрне файдалануның билгеләнгән режимын бозган өчен хокукый затларга - егермедән алып илле минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр, гражданнарга бердән алып биш минималь айлык хезмәт хакы күләменә кадәр штраф салына.

10 статья. Җир турындагы законнарны бозган өчен җаваплылык

Җир турындагы законнарны әлеге Законда күрсәтелгәнчә бозулар өчен, әгәр бу хокук бозулар гамәлдәге законнар нигезендә җинаять җаваплылыгына китермәсә, административ җаваплылык билгеләнә.

Штрафлар салу һәм башка җәзалар билгеләү гаепле кешеләрне кылган хокук бозуларның юкка чыгарылуыннан һәм китергән зыяннарын, югалтылган табышны да кертеп, түләүдән азат итми.

II статья. Җир турындагы законнарны бозган өчен хокукый һәм физик затларны җаваплылыкка тарту тәртибе

Әлеге Законның I,2,4,5,6,8 статьяларында күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы беркетмәләр - Җир байлыклары һәм җир реформасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының һәм аның җирле органнарының,Урман хуҗалыгы министрлыгы һәм аның җирле органнарының урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан; 3 статьяда /сәнәгать калдыклары, агып төшкән сулар, агулы һәм радиоактив матдәләр белән җирне пычрату өле-

шендә/, 7, 9 статьяларда күрсәтелгән хокук бозулар турында – Татарстан Республикасының Тирә-як мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгының һәм аның җирле органнарының вәкаләтле затлары тарафыннан; 3 статьяда /бактериаль-паразитик һәм карантин организмнары белән җирләрне пычрату өлешендә/ күрсәтелгән хокук бозулар турында Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитетының һәм аның җирле органнарының урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан; I, 4, 7 статьяларда күрсәтелгән хокук бозулар турында беркетмәләр архитектура-төзелеш күзәтүен гамәлгә ашыручы органнарның урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан төзелә.

Әлеге Законда күрсәтелгән административ хокук бозулар турындагы эшләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта Җир байлыклары һәм җир реформасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты, Татарстан Республикасының Тирә-як мохитне саклау һәм табигый байлыклар министрлыгы, Санитария-эпидемиология күзәтүе буенча Татарстан Республикасы дәүләт комитеты һәм аларның җирле органнары, шулай ук архитектура-төзелеш күзәтүенең җирле органнары тарафыннан карала.

Үзенә карата әлеге гамәлләр кылынырга тиешле зат җирне файдалануны һәм аны саклауны дәүләт тарафыннан тикшерүче югарырак органга яисә судка комиссиянең штраф салу турындагы карары хакында шикаять белән мөрәҗәгать итә ала.

12 статья. Җир турындагы законнарны бозган өчен штрафлар түләү рәвешендә кергән акчаларны тоту

Штрафлар түләү рәвешендә кергән акчалар бары тик җирне саклау, авыл хуҗалыгы җирләрен яхшырту, туфракның уңдырышлылы-

гын арттыру, төрлечә бозылган җирләрне торгызу, пычранган территорияләрне башлангыч торышына кайтару максатларында, шулай ук проектлау-эзләнү, фәнни тикшеренү эшләрен һәм әлеге гамәлләрне тормыша ашыру һәм җирләрне саклауны һәм файдалануны дәүләт тарафыннан тикшереп тору белән бәйле башка эшләрне башкару өчен, әлеге тикшерүләрне уздыручы органнарны матди-техник тәэмин итү өчен кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М. Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 9 феврале
№ 2079-ХП